КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 5 май г.Казань № 321

Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб төзү турында

Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү барышында барлыкка килә торган мәсьәләләрне кичектергесез карап тикшерүне һәм хәл итүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 декабрь, б-3141 нче боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 май, 321 нче
карары белән расланды

# Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб (алга таба – оператив штаб) Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары В.Л.Мутко тарафыннан 2017 елның 8 июнендә 3988п-П12 номеры белән расланган 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын үткәрү белән идарә итү системасы концепциясе нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында төзелгән күмәк орган булып тора.

1.2. Оператив штабны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе җитәкли.

1.3. Оператив штаб үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокук актларына, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка хокук актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 2. Оператив штабның бурычлары һәм вәкаләтләре

Оператив штаб:

2.1. Татарстан Республикасы территориясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын (алга таба – Чемпионат) (тест чараларын һәм FIFA Җанатарлар фестивален дә кертеп) әзерләү һәм үткәрү чорында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр, башка оешмалар эшчәнлеге хезмәттәшлеген тәэмин итә.

2.2. Татарстан Республикасы территориясендә Чемпионатка бәйле булган чараларны оештыруда һәм үткәрүдә «Россия-2018» оештыру комитеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасына булышлык күрсәтә.

2.3. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм Чемпионат матчларын һәм тест чараларын үткәрү чорында «Казан Арена» стадионы янындагы территориядә автотранспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне тәэмин итү буенча үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка кызыксынучы оешмалар хезмәттәшлеген оештыра.

2.4. 2017 елның 8 июнендә 3988п-П12 номеры белән расланган 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын үткәрү белән идарә итү системасы концепциясе нигезендә кирәкле ресурслар бирүне һәм гамәлләр башкаруны, Татарстан Республикасы территориясендә штаттан тыш вәзгыятьне җайга салу планнарын үтәүне оештыруны тәэмин итә.

2.5. Татарстан Республикасы территориясендә сәүдә, җәмәгать туклануы, медицина, транспорт һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәләрендә хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын, шулай ук Казан шәһәрендә коммуналь инфраструктура объектлары эшләвен мониторинглауны гамәлгә ашыра.

2.6. Чемпионат үткәрү чорында Казан оештыручы-шәһәрендә мәдәни-массакүләм чараларны үткәрүне мониторинглауны, шул исәптән FIFA Җанатарлар фестивален әзерләү эшләрен яраштыруны гамәлгә ашыра.

2.7. Вәкаләтле вәкил аша төбәк операция үзәге (алга таба – Төбәк үзәге) һәм Төбәк үзәгендәге башка оператив штабларның вәкаләтле вәкилләре белән, иминлекне тәэмин итү буенча ведомствоара оператив штаб, иминлекне тәэмин итү буенча төбәк ведомствоара оператив штаб, баш операция үзәге белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

2.8. Төбәк үзәгенә вәкаләтле затларны билгели.

2.9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1056 нчы карары белән расланган 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнү программасын, Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү буенча «Россия 2018» республика оештыру комитеты утырышының 2018 елның 19 мартындагы ПР-69 номерлы беркетмәсе белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын һәм 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын тәэмин итү һәм үткәрү чараларының комплекслы планын, Татарстан Республикасына кагылышлы өлештә Россиядә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрүгә әзерләнүнең «юл картасы»н, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары В.Л.Мутко белән расланган 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын тәкъдим итү буенча 2017 елның 7 октябрендәге 7204п-П12 номерлы чаралар планын, 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын үткәрү кысаларында стадион янындагы территориядә операция эшчәнлеге планын үтәүне, шулай ук спорт тест чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча үзара хезмәттәшлекне һәм яраштыруны тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

2.10. Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын әзерләү һәм үткәрү буенча «Россия 2018» республика оештыру комитеты утырышының 2018 елның 19 мартындагы ПР-69 номерлы беркетмәсе белән расланган Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын үткәрү чорында Казан шәһәрендә йөртүләр белән идарә итү планы үтәлешен оештыра.

2.11. Оператив штаб компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, оешмалардан билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат соратып ала.

2.12. Оператив штаб утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен (килешү буенча), федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләрен (килешү буенча), оешмалар җитәкчеләрен һәм тулы вәкаләтле вәкилләрен (килешү буенча) чакыра һәм оператив штаб компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тыңлый, тиешле карарлар кабул итә.

2.13. Оператив штаб компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне карап тикшерү өчен экспертлар (белгечләр) җәлеп итә.

## 3. Оператив штаб составы

3.1. Оператив штаб составына оператив штаб җитәкчесе һәм аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашучы башка әгъзалар керә.

3.2. Оператив штаб, бу Нигезләмәнең таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан төзелә.

3.3. Оператив штаб җитәкчесе:

оператив штаб эшен оештыра, оператив штаб утырышларында мәсьәләләрне карап тикшерү вакытларын, тәртибен һәм аларның исемлеген билгели;

оператив штаб әгъзалары арасында вәкаләтләрне (йөкләмәләрне) бүлә;

утырышның көн тәртибен, аны үткәрү көнен, урынын һәм вакытын билгели һәм раслый;

үзе булмаган вакытта оператив штаб җитәкчесе вазыйфасын башкаручыны билгели.

3.4. Оператив штаб составына эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендә функцияләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары җитәкчеләре урынбасарлары, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының җаваплы вазыйфаи затлары (килешү буенча), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының җаваплы вазыйфаи затлары (килешү буенча), башка органнар һәм оешмаларның җаваплы вазыйфаи затлары (килешү буенча) кертелә.

3.5. Оператив штаб әгъзалары оператив штаб эшендә шәхсән катнаша.

## 4. Оператив штаб утырышлары һәм карарлары

4.1. Оператив штаб утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә.

4.2. Оператив штаб утырышларын җитәкче яки аның вазыйфаларын башкаручы алып бара.

4.3. Оператив штаб утырышын, карап тикшерелә торган тематикадан чыгып, тулы составта да һәм кыскартылган составта да үткәрергә мөмкин.

4.4. Оператив штаб карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Оператив штаб утырышлары беркетмәләренә оператив штаб җитәкчесенең (ул булмаганда –

аның вазыйфаларын башкаручының) имзасы куела һәм өч көн эчендә кызыксынучы хакимият органнарына, оешмаларга һәм вазыйфаи затларга җибәрелә.

## 5. Оператив штаб эшчәнлеген тәэмин итү

5.1. Оператив штаб эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләнә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 5 май, 321 нче
карары белән расланды

Казан шәһәрендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионаты чараларын әзерләү һәм үткәрү буенча оператив штаб составы

| | |
|---|---|
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оператив штаб җитәкчесе |
| Габдрәшитов Артур Игоревич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары |
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Вандюков Дмитрий Владимирович | Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының беренче урынбасары |
| Варакин Евгений Анатольевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гәрәев Раил Рүзәл улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген яраштыру идарәсе башлыгы |
| Громушкин Пётр Николаевич | Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгының беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасының футбол буенча дөнья чемпионатына әзерләнү буенча департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Егоров Андрей Вячеславович | Татарстан Республикасының транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Зарипов Раушан Булат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә караган физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре бүлекчәсе мөдире |
| Ивачев Роман Евгеньевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты аппаратының спорт проектларын тормышка ашыру бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кадыйров Азат Рифгать улы | «Россия-2018» оештыру комитеты» коммерциягә карамаган автоном оешмасының Казан оештыручы-шәһәрендәге чаралар объектларын әзерләү һәм аларны оештыру идарәсе җитәкчесе, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Кадыйров Рөстәм Рәиф улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы |
| Коростелёв Сергей Владимирович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының эшләр идарәчесе |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Маврина Лилия Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре (килешү буенча) |
| Минголов Алмаз Минвазыйх улы | Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары |
| Миңнәхмәтов Радик Җәүдәт улы | «Казан Арена» акционерлар җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Савельев Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Садриев Илдар Зөфәр улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасары |

| | |
|---|---|
| Сергеев Сергей Валентинович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – күзәтү эшчәнлеге идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Трофимова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Фәйзрәхманов Марат Габделкави улы | Татарстан Республикасы Президентының Иминлек хезмәте хезмәткәре (килешү буенча) |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Фатыйхов Илдар Разин улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары |
| Фәтхуллин Марат Наил улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының эре халыкара спорт чаралары иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хөсәенов Алмаз Шәүкәт улы | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары |
| Шакирова Гүзәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы. |

______________________________